КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 6 март г.Казань № 176

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 21 август, 724 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 21 август, 724 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 июнь, 381 нче; 2014 ел, 31 декабрь, 1093 нче; 2016 ел, 15 февраль, 91 нче; 2016 ел, 2 июль, 454 нче; 2016 ел, 19 сентябрь, 654 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1065 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1046 нчы; 2018 ел, 20 июнь, 502 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле

оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктка «оешмалар» сүзеннән соң «, индивидуаль эшмәкәрләр» сүзләрен өстәргә, «туристлык оешмалары» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 нче пунктка «максатларында» сүзеннән соң «, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 21 июль, 522 нче карары белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасы кысаларында» сүзләрен өстәргә;

3 һәм 4 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы теләсә кайсы хокук рәвешендәге юридик затлар (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш), индивидуаль эшмәкәрләр (алга таба – туристлык оешмалары) субсидияләр алырга хокуклы.

Бу Тәртиптә гариза бирүчеләр – ул бу пунктның беренче абзацы нигезендә субсидия алырга хокуклы һәм аны алуга дәгъва итүче туристлык оешмаларын аңлата.

Бу Тәртиптә субсидия алучылар булып субсидия бирү турында карар кабул ителгән гариза бирүчеләр тора.

4. Субсидияләр бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм тиешле финанс елына субсидия бирү өчен бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.»;

5 нче пунктта:

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эчке һәм читтән килүчеләр туризмы базарларында Татарстан Республикасының туризм мөмкинлекләрен чыгаруга юнәлдерелгән реклама чараларын үткәрүне оештыруга чыгымнар;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасының туристлык ресурслары турында реклама-мәгълүмати материаллар (шул исәптән чит телләрдә) эшләүгә чыгымнар;

Татарстан Республикасы экскурсоводлары һәм гид-тәрҗемәчеләре өчен белем бирү чараларын үткәрүгә чыгымнар (квалификация күтәрү курслары, укыту семинарлары, мастер-класслар, тренинглар һ.б.);

Татарстан Республикасының туризм базарына махсус тикшеренүләр үткәрүгә чыгымнар;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең социаль челтәрләрендә һәм башка челтәр берләшмәләрендә Татарстан Республикасының туристлык ресурсларын мәгълүмати таратуга чыгымнар;

Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә яңа, шул исәптән инновацияле проектны (программаларны, материалларны) тормышка ашыруга турыдан-туры бәйле булган башка чыгымнар.»;

6 нчы пунктта:

дүртенче абзацта «субсидияне файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең мәгънәләре, субсидияне файдалану һәм субсидияне файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык бирү формалары һәм вакытлары» сүзләрен «субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләрнең мәгънәләре, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләргә һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисаплылык бирү, субсидия алучыларның өстәмә хисаплылык бирү вакытлары һәм формалары» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Субсидия бирү турындагы килешү белән күздә тотылган чыгымнарның күләмнәре кимегән очракта, бирелә торган субсидиянең күләмен үзгәртү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма буенча субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү проекты субсидия алучыга чыгымнарның күләмнәрен киметү турында мәгълүмат бирелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә җибәрелә.

Субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты тарафыннан субсидия алучыдан аның ягыннан имзаланган өстәмә килешүне алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә имзалана.»;

7 нче пунктның беренче абзацында «кредит оешмасында ачылган» сүзләре алдына «Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә яки» сүзләрен өстәргә;

9 нчы пунктта:

сигезенче абзацта «2014 – 2020 елларга» сүзләрен «2014 – 2022 елларга» сүзләренә алыштырырга;

унбишенче абзацта татар текстында «бетерү, банкротлык процессында тормый,» сүзләрен «бетерү процессында тормый,» сүзләренә алыштырырга, алардан соң «аңа карата банкротлык процедурасы гамәлгә кертелмәгән, юридик затның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган» сүзләрен өстәргә;

10 нчы пунктның икенче абзацында татар текстында «чыгымнарның исәп-хисапларын һәм нигезләмәләрен теркәп,» сүзләреннән соң «чыгымнар күләмен нигезли торган мәгълүматны, шулай ук аны алу чыганагын (тәңгәл (бер үк төрле) товарларның, эшләр башкаруның, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турында аналитик мәгълүмат, шул исәптән җитештерүче оешмаларның бәяләре турындагы, дәүләт статистикасы органнарындагы, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларындагы һәм махсус әдәбияттагы (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) бәяләр дәрәҗәсе турында мәгълүмат) күрсәтеп,» сүзләрен өстәргә.

$10^1$ нче пунктның алтынчы абзацында татар текстында «бәяләнә» сүзе алдына «Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты тарафыннан расланган форма нигезендә бәяләү кәгазенә баллар кертү юлы белән» сүзләрен өстәргә;

11 нче пунктта:

икенче абзацта «һәм эшчәнлеге тәртибе» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты заявканы теркәлгән документлары белән алар кергән көннән бер эш көне эчендә кабул итә һәм терки.»;

җиденче абзацта «Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты» сүзләреннән соң «боерык рәвешендә» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Конкурс комиссиясе утырышының көне һәм вакыты Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты карары белән билгеләнә. Әлеге мәгълүмат, конкурс комиссиясе утырышы үткәрелә торган көнгә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының рәсми сайтында (http://tourism.tatarstan.ru/) урнаштырыла.

Конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре белән шәхсән кызыксынган затлар (шул исәптән заявкалар тапшырган йә заявкалар тапшырган туристлык оешмалары штатында торган) йә конкурс нигезендә сайлап алуда катнашучылар йогынты ясарга сәләтле затлар конкурс комиссиясе әгъзалары була алмый.

Конкурс нигезендә сайлап алуда катнашуга бер заявка да кермәгән очракта, конкурс нигезендә сайлап алу үткәрелмәгән дип санала.

Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр дә анда комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, тулы хокуклы була.

Конкурс комиссиясе утырышына заявкадагы мәгълүмат буенча аңлатмалар бирү өчен заявка тапшырган туристлык оешмалары вәкилләре чакырылырга мөмкин.

Конкурс комиссиясе заявка бирүчеләрнең тапшырылган документларын карап тикшерә һәм, заявкаларны бу Тәртипнең $10^1$ нче пунктында күрсәтелгән бәяләү критерийлары нигезендә бәяләп, конкурс нигезендә сайлап алуга йомгаклар ясый.

Әлеге критерийлар буенча конкурс комиссиясе әгъзалары, конкурс нигезендә сайлап алуны үткән заявкаларны күрсәтеп, карап тикшерелгән һәм, баллар җыю саны кимүгә карап, рангларга бүленгән заявкалар исемлеген формалаштыра.

Конкурс комиссиясенең үткәрелгән конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре турындагы карары конкурс комиссиясе утырышын үткәргән көннән өч эш көне эчендә, конкурс нигезендә сайлап алуны үткән гариза бирүчеләрне күрсәтеп, беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә, конкурс комиссиясе утырышында карап тикшерелгән заявка бирүчеләр (иң күп баллдан башлап, җыйган баллар саны буенча) күрсәтелә торган кушымтасы аның аерылгысыз бер өлеше булып тора.

Конкурс комиссиясенең барлык әгъзалары үз эшчәнлеген түләүсез нигездә башкара, конкурс комиссиясе әгъзасы вәкаләтләрен башка затка бирү рөхсәт ителми. Конкурс комиссиясе утырышында кабул ителгән карар белән килешмәгән конкурс комиссиясе әгъзалары аерым фикерен язмача бәян итәргә мөмкин, ул утырыш беркетмәсенә теркәлә.

Конкурс комиссиясенең гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына карата туристлык оешмасы тарафыннан законнар белән билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

Әгәр дә агымдагы финанс елында, бу Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары җитмәүгә бәйле рәвештә, субсидия бирү мөмкинлеге булмаганда, чираттагы финанс елында субсидия бу Тәртипнең $10^1$ нче пунктында күрсәтелгән заявкаларны бәяләү критерийларына туры килүче субсидия алучыга

заявкаларны бәяләүнең әлеге критерийларына туры килү-килмәүгә яңадан тикшерү үтмичә бирелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 11[1] нче пункт өстәргә:

«11[1]. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 21 июль, 522 нче карары белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасына теркәлгән кушымтаның 3.4 нче пункты нигезендә агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә яңа (шул исәптән инновацияле) проектны (программаны, материалларны) тормышка ашыру субсидия бирүнең нәтиҗәсе булып тора.»;

12 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле түбәндәге күрсәткечләрнең мәгънәләре нигезендә билгеләнә:

субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә яңа (шул исәптән инновацияле) проектны (программаны, материалларны) тормышка ашыру вакытлары үтәлү;

субсидия алучы тарафыннан тормышка ашырылган Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә яңа (шул исәптән инновацияле) проектка (программага, материалларга) җәлеп ителгән максатчан аудиторияне колачлау саны;

субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә яңа (шул исәптән инновацияле) проектны (программаны, материалларны) тормышка ашыру йомгаклары буенча массакүләм мәгълүмат чараларында (шул исәптән электрон) һәм (яки) социаль челтәрләрдә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге башка челтәр берләшмәләрендә басмалар саны.

Субсидияләр алучылар Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына түбәндәгеләрне кертә:

агымдагы финанс елының соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча кәгазь чыганакта субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләргә һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисаплылык;

субсидия бирү турындагы килешү белән билгеләнгән форма һәм вакытлар нигезендә финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисаплылык.

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты субсидия бирү турындагы килешүдә алучының өстәмә хисаплылык бирү вакытларын һәм формаларын билгеләргә хокуклы.»;

13 нче пунктның беренче – бишенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Бирелгән субсидияләр Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының тиешле таләбе субсидия алучы тарафыннан алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә түбәндәге очракларда Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш:

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия бирү турындагы килешү белән билгеләнгән шартларны бозу фактлары ачыкланганда;

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына дөрес булмаган мәгълүмат бирелгәндә;

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты тарафыннан соратыла торган мәгълүмат һәм документлар тапшырылмаганда;

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнә торган, бу Тәртипнең 12 нче пунктында күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләрнең мәгънәләренә, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгәндә.»;

түбәндәге эчтәлекле 15 нче пункт өстәргә:

«Субсидия бирү турында төзелгән килешү Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты һәм субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип форма буенча субсидия бирү турындагы килешүне өзү хакындагы өстәмә килешүгә имза кую юлы белән өзелә (кирәк булганда).»;

Тәртипкә кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

Форма

___________________________________________________________________________

(субсидия алучының тулы исеме)

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләрнең мәгънәләренә һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисабы

| Т/с | Нәтиҗә исеме | Күрсәткеч исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы буенча үлчәү берәмлеге | | Күрсәткечнең план буенча мәгънәсе | Хисап көне хәленә карата күрсәткечнең ирешелгән мәгънәсе | Планны үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | исеме | коды | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләрнең мәгънәләренә һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүне раслый торган документлар:

1. ________________________________________________________________;
2. ________________________________________________________________.

Субсидия алучының җитәкчесе
(вәкаләтле зат) ________________ ____________ ____________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

М.У. (булганда)

Үтәүче ________________ ________________ ______________________ ________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу) (телефоны)

20__ елның «_____» _____________

___________________________________